**Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарында**
**2023 елның 9 аенда гражданнар мөрәҗәгате белән эшләү турында**
**мәгълүмат**

2023 елның 9 аенда Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарында гражданнардан язмача җибәрелгән һәм шәхси кабул итүләрдә алынган **5900** мөрәҗәгать карап тикшерелде (2022 елда – **6061**).

Барлык мөрәҗәгатьләрнең **3569** ы – язмача кергән мөрәҗәгатьләр (2022 елда – 3873), шул исәптән Интернет-кабул итү һәм электрон почта аша – **2330** мөрәҗәгать.

Шәһәр Хакиме һәм Башкарма комитет Җитәкчесе адресына 8151 кешедән 163 коллектив мөрәҗәгать керде.

**3569** мөрәҗәгатьнең **659** ы уңай хәл ителде, бу гомуми санның 19,3% ын тәшкил итә, **140** мөрәҗәгать ведомство буйсынуындагы оешмаларга адресланды; калганнары буенча аңлатмалар һәм рекомендацияләр бирелде.

Үзләренең социаль хәлен күрсәтүче гражданнарның составы түбәндәге категорияләр белән күрсәтелә:

- эшләүчеләр: 235 (6,58 %);
- пенсионерлар: 165 (4,62 %);
- интеллигенция: 54 (1,51 %);
- эшмәкәрләр: 45 (1,26 %);
- хезмәткәрләр: 33 (0,93 %);
- хуҗабикәләр: 31 (0,87 %);
- эшсезләр: 24 (0,67 %);
- укучылар: 1 (0,03 %);
- социаль хәлен күрсәтмәүчеләр: 2981 (83,53 %).

Мөрәҗәгать итүчеләр арасында үзенең ташламалы категориягә ия булуын күрсәтүчеләрнең күпчелеген күп балалы гаиләләр – **87** (2,44 %), инвалидлар – **86** (2,41 %), хәрби хәрәкәт ветераннары – **13** (0,36 %), качаклар – **5** (0,14 %) тәшкил итә.

Гражданнардан язмача алынган мөрәҗәгатьләрне анализлау шуны күрсәтә, шәһәр халкы өчен түбәндәге мәсьәләләр актуальрәк булып саналган:

- торак-коммуналь хуҗалык – 1247 (2022 – 1403);
- юл хуҗалыгы – 344 (2022 – 391);

- мәгариф һәм мәктәпкәчә тәрбия – 258 (2022 – 252);

- җирдән файдалану – 236 (2022 – 313);

- төзелеш – 233 (2022 – 260);

- социаль тәэмин итү – 184 (2022 – 194);

- транспорт хезмәте күрсәтү – 183 (2022 – 130);

- торак өлкәсе – 179 (2022 – 202);

- сәламәтлек саклау – 133 (2022 – 118);

- сәүдә һәм кулланучылар хезмәте – 121 (2022 – 150);

- законлылыкны һәм хокук тәртибен тәэмин итү – 98 (2022 – 93);

- финанс өлкәсе – 81 (2022 – 94);

- РФ Кораллы Көчләрендә хезмәт итү мәсьәләләре – 50 (2022 – 27);

- хезмәт һәм мәшгульлек – 39 (2022 – 60);

- элемтә мәсьәләләре – 37 (2022 – 50);

- башкалар – 146 (2022 – 136).

Шәхси кабул итү хакимият органнарының гражданнар белән кирәкле аралашу формасы булып кала. **2 331** чаллылы нәкъ шул формадан файдаланган (2022 елда – **2 188**).

**796** мөрәҗәгать буенча кирәкле чаралар күрелде, бу гражданнардан кабул ителгән мөрәҗәгатьләрнең **34,1 %** ын тәшкил итә. Мөрәҗәгать иткән **1510** граждан аңлатмалар алды, **25** мөрәҗәгать контрольдә тора.

Муниципаль берәмлек җитәкчеләре тарафыннан **233 кеше** кабул ителде (2022 елда – **184**):

- Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев тарафыннан – **74** кеше (2022 – 83);
- Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары И.А. Сәгыйдуллина тарафыннан – **21** кеше (2022 – 5);
- Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов тарафыннан – **128** кеше (2022 – 96).

Гражданнар һәр атнаның сишәмбесендә түбәндәгечә кабул ителә:

- Шәһәр Хакиме, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан кабул итү – 16.00 дән 18.00 сәгатькә кадәр, Академик Рубаненко, 7 йорт адресы буенча шәһәр Хакименең Җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәсендә;

- Шәһәр Хакиме ярдәмчесе (халык белән эшләү буенча) тарафыннан кабул итү – шимбә һәм якшәмбедән кала һәр көнне 08.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр (төшке аш вакыты 12.00 – 13.00 сәгатьләрдә), Академик Рубаненко, 7 йорт адресы буенча шәһәр Хакименең Җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәсендә;
- район хакимиятләре Башлыклары тарафыннан (район хакимиятләренең урнашу урыны буенча) кабул итү – 14.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр;
- Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарлары, идарә башлыклары тарафыннан кабул итү – 14.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт адресы буенча шәһәр хакимияте бинасында.

Җирле үзидарә органнарында гражданнарның бер генә мөрәҗәгате дә игътибарсыз калмый.

Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрнең мониторингы һәр көнне уздырыла, аларны үз вакытында карауга контрольлек гамәлгә ашырыла, башкару дисциплинасы анализлана.

Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрдә бәян ителгән мәсьәләләр компетенция кысаларында оператив рәвештә хәл ителә.

Һәр мөрәҗәгать итүчегә гамәлдәге законнар нигезендә язмача җаваплар һәм аңлатмалар бирелә.